ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ДРОЖЖАНОВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЧҮПРӘЛЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

19.07.2021 с.Старое Дрожжаное № 288

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Зур Аксу авыл җирлегенең Генераль планы проектын эшләү турында

Территориянең тотрыклы үсешен тәэмин итү максатларында, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 23, 24 статьяларына, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14, 15 статьяларына, «Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2017 елның 31 декабрендәге 507-ФЗ номерлы Федераль законга, Россия Федерациясе икътисадый үсеш Министрлыгының 2018 елның 9 гыйнварындагы 10 номерлы боерыгына таянып, Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Зур Аксу авыл җирлегенең Генераль планы проектын эшләүгә керешергә.
2. Әлеге карарны «Туган як» район газетасында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (https://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә) һәм «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Чүпрәле муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга (https://drogganoye.tatarstan.ru).
3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктура үсеше буенча урынбасары И.С. Бикчуровка йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе вазыйфаларын башкаручы И.Р. Измайлов